**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

IV чакырылыш                    чираттан тыш утырыш

“28” гыйнвар 2021 ел                    №29                    Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2018 елның 26 июнендәге №20 карары белән кабул ителгән "Хезмәт (вазифаи) тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмә"гә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» Россия Федерациясе Президентының 01.07.2010 № 821 Указы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2007 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урыннарында үз-үзләрен тотышына таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча комиссия турында» 2010 елның 25 июлендәге 569 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.04.2020 ел, № 18 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2018 елның 26 июнендәге №20 карары белән кабул ителгән «Хезмәт урынындагы (вазыйфаи) тәртипкә таләпләрне һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмә"гә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәүгә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне комиссия тарафыннан карау тәртибе» 3 бүлегенең 3.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.2.6 пунктча өстәргә:

«3.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» һәм «д» пунктчаларындагы икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүматны;

б) гарызнамәләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүматны;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11.1 пунктларына ярашлы карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәрне.».

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм Татарстан Республикасы Ютазы районы җирлекләре Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин